РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Вахитовского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д. 30,
Азнакаевский район, п.Победа,
423312,
тел./факс (885592)42-1-38
E-mail: Vahit.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге
башлыгы

Үзәк ур., 30 йорт, Азнакай районы,
Җиңү бистәсе, 423312
тел./факс (885592)42-1-38
E-mail: Vahit.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«19» март 2026 ел.** **№ 1**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Советының "2025 елгы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджет үтәлеше турында" карар проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында

Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегендә яшәүчеләрнең Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең 2022 елгы бюджет үтәлеше турында» карар проектын гавами тыңлауларда фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Вахит авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Советының 2012 елның 21 апрелендәге 42 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахит авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Советының "2025 елгы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджет үтәлеше турында" карар проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләргә. (1 нче кушымта).

2. Гавами тыңлауларны үткәрү инициаторы - Азнакай муниципаль районының Вахит авыл җирлеге Башлыгы.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты - 2026 елның 16 апрелендә 15.00 сәгатьтә;

- үткәрү урыны – түбәндәге адрес буенча урнашкан Вахит авыл җирлеге Башкарма комитеты: Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Җиңү бистәсе, Үзәк ур., 30;

– фикер алышынган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла торган адрес: 423312, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Җиңү бистәсе, Үзәк ур., 30.

4. Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Башкарма комитетына:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Советының "Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең 2025 елгы бюджет үтәлеше турында" карар проекты буенча гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда гавами тыңлауларны әзерләргә һәм үткәрергә;

- 2026 елның 25 мартыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Советының "2025 елгы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджет үтәлеше турында" карар проектын (1 нче кушымта) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatarstan.ru.

5. 2026 елның 30 мартыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча»: http://aznakaevo.tatar.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз естемдә калдырам.

Башлык Г.И. Әскәрова